**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның «30» октябре** **№55/1**

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Яуширмә
авыл җирлеге Советының 02.10..2015
елгы “ Физик затлар мөлкәтенә салым турында”гы

3/1 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексына кертелгән үзгәрешләр нигезендә, Чистай шәһәр прокуратурасының 22.10.2018 елгы 02-08-02-2018 нче номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге Советының 02.10.2015 елгы“ Физик затлар мөлкәтенә салым турында”гы 3/1 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 пунктта:
1.1.1.2нче пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге яңа абзац белән тулыландырырга:
«-фатир өлешләре»;
1.1.2.3 пунктчаның дүртенче абзацында « бер торак бина (торак йорт)» дигән сүзләрне «бер торак йорт» дигән сүзләргә алмаштырырга;
1.1.3. 3пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге яңа абзац белән тулыландырырга:
«- торак биналар өлешләре»;
1.2. 2.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. ике фатирдан яисә фатир өлешләреннән торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирлар яки фатир өлешләре хуҗаларына исәпләнгән салымны әлеге фатирның яки фатир өлешенең гомуми мәйданының утыз квадрат метрының кадастр бәясендәге салым ставкасының процент өлешен билгеләүче суммага киметү төрендә ташлама бирелә. Әгәр фатир яки фатир өлешләре уртак өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәрберсенә әлеге фатир яки фатир өлешләренә милеккә хокуктагы өлешенә пропорциональ исәпләнә.

Әгәр фатир яки фатир өлешләре гомуми уртак милектә булса, ташлама суммасы уртак милектә катнашучыларның һәрберсенә тигез өлешләрдә исәпләнә. Шуның белән бергә әлеге пункт нигезендә саналган сумма аны исәпкә алмыйча исәпләнгән суммадан артмаска тиеш»;

1.3. 2.2 пунктын түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«2.2. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

2.2.1. 18 яшькә кадәр биш һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар;

2.2.2. Әлеге пунктның 2.2.1. пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балалары»;

1.4. түбәндәге эчтәлектәге 2.3 пункты белән тулыландырырга:

«2.3. Салым түләүчеләрнең Россия Федерациясе Салым кодексында карарлган башка категорияләренең дә салым ташламасына хокукы бар».

2. Әлеге карарны ТР Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына элү юлы белән бастырырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмати- телекоммуникацион челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктлары йогынтысы 2017 елның 1 гыйнвареннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләү белән бәйле хокукмөнәсәбәтләренә тарала, әлеге карарның 2019 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керүче 1.1.2. пунктчасыннан кала, әмма әлеге карарны рәсми бастырган көннән бер ай узганнан соң. Әлеге карарның 1.3 пункты йогынтысы 2018 елның 1 гыйнвареннан физик затларга салым исәпләү белән бәйле хокукмөнәсәбәтләренә тарала.

ТР Чистай муниципаль районы
Яуширмә авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Гәрәева